Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Писмән авыл җирлеге
Дала Зәе авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 21 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дала Зәе авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 21 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге территориясендә Дала Зәе авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Беек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:
җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Дала Зәе авылында юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
- Дала Зәе авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;
«ӘЙЕ» «ЮК»

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе тезелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 63 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 442кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлегенең Дала Зәе авылында гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге составына керүче Дала Зәе авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дерес дип танырга.
2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Писмән авыл җирлеге Дала Зәе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, Беек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан тыш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:
җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль

юлларына карата юл эшчәнлеге:
- Дала Зәе авылында юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту) ;
- Дала Зәе авылы территориясен төзекләндерүне оештыру;карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин урамы, 5 йорт, Югары Каран авылы Үзәк урам 50 йорт – авыл мәдәният йорты, 1нче адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.В.Насретдинов